Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Исполнительный комитет
Брюшлинского сельского поселения

Татарстан Республикасы
Менделевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлеге
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
2020 елның 16 июленнән

КАРАР
№16

Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Башкарма комитетының Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча 2020 елның 5 февраленнән 5 номерлы карары белән расланган документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.5 пунктындагы 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Күләме бер биттән артып киткән күчермәләрнең яки алардан өземтәләрнең тугрылыгын таныклау өчен тапшырылган документлар беркетелергә тиеш. Документта булган төзәтмәләр яки башка җитешсезлекләр документ тәкъдим ителгән максатлар өчен мөһим булмаса, җирле үзидарәнең вазыйфаи заты мондый документны күчермәнең дөреслеген таныклау өчен кабул итәргә хокуклы.»;

1.2. Административ регламентның 2.8 пунктының 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) мондый гамәлне кылу Россия Федерациясе законнарына каршы килә;

2) гамәл башка җирлек, муниципаль, шәһәр округы яисә муниципаль район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты тарафыннан (нәселдәнлек мөлкәтен саклау буенча чаралар күрүгә карата) яисә нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;

3) нотариаль гамәл кылу турындагы үтенеч белән хокукка сәләтсез граждан йә кирәкле вәкаләтләре булмаган вәкил, яшәү яисә булу урыны буенча теркәлүе булмаган граждан мөрәҗәгать иткән;

4) ышанычнамә Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;

5) нотариаль гамәл башкару өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;

6) нотариаль гамәл кылу өчен тапшырылган документларда бәян ителгән фактлар раслану Россия Федерациясе законнары нигезендә таләп ителгән очракта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган.»;

1.3. Административ регламентның 2.9 пунктындагы 8 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылганда, физик һәм юридик затлар өчен Россия Федерациясе Салым Кодексының 333.35 статьясындагы 1 пунктының 11, 12 пунктчаларында, 333.38 статьясында билгеләнгән дәүләт пошлинасын түләү буенча ташламалар бирелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Бөрешле авыл җирлеге Башлыгы Л.А. Смирнова